ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09 04 2021 г. № 390

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 7 декабрендәге 1031 номерлы карары белән расланган «Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) тормышка ашыручы белем бирү учреждениеләренә (оешмаларга) исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карарына таянып, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 7 декабрендәге 1031 номерлы карары белән расланган «Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) тормышка ашыручы белем бирү учреждениеләренә (оешмаларга) исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 бүлегендәге 3.4.6 пунктының икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Оешмаларны чираттагы уку елына туплау чираттагы уку елына расланган төркемнәр саны һәм аларда буш урыннар нигезендә агымдагы елның 1 июненнән 31 августына кадәр башкарыла. Системада туплаганда балаларның яше агымдагы елның 1 ноябренә исәпләнә. Буш урыннар булса, белем бирү оешмасына кабул итү календарь ел дәвамында гамәлгә ашырыла.».

Әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә, «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмалары турында мәгълүматлар» Регламентына 1 нче кушымтасына 74.1, 74.2 пунктларын өстәргә.

Регламентка 1 нче кушымта «Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар» бүлегенә әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә юллар өстәргә.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында матбугат басмасында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе җитәкчесе Р.М. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкче урынбасары Р.Ә. Хаҗиев

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 9 нчы апрель
390 нчы номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмалары турында мәгълүматлар

| № | Оешма исеме | Ф.И.А. | Телефон номеры | Адрес/ оешма сайты | Оешманың эш режимы, җитәкченең кабул итү сәгатьләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 74.1 | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Баланы үстерү үзәге - 98 нче «Калейдоскоп» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Әдиатуллина Гүзәл Рафикъ кызы | (88555) 44-78-00 | Түбән Кама шәһәре, Химиклар пр., 11 https://edu.tatar.ru/nkamsk/org6869 | Биш көнлек эш атнасы 6:00 дән 18:00 гә кадәр Кабул итү сәгатьләре: дүшәмбе 16:00-18:00 җомга 8:00-10:00 |
| 74.2 | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Баланы үстерү үзәге - 99 нчы «Күбәләк» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Таҗетдинова Лилия Габделфәт кызы | (88555) 44-78-01 | Түбән Кама шәһәре, Чишмале ур., 21 https://edu.tatar.ru/nkamsk/org6870 | Биш көнлек эш атнасы 6:00 дән 18:00 гә кадәр Кабул итү сәгатьләре: дүшәмбе 16:00-18:00 җомга 8:00-10:00 |

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 9 нчы апрель
390 номерлы карарына
2 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм анның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар

| Вазыйфаи затның Ф.И.А. | Вазыйфа | Адрес/ оешма сайты | Телефон | Оешманың эш режимы, вазыйфаи затның кабул итү сәгатьләре |
|---|---|---|---|---|
| Әдиатуллина Гүзәл Рафикъ кызы | Мөдир | Түбән Кама шәһәре, Химиклар пр., 11<br>https://edu.tatar.ru/nkamsk/org6869 | (88555)<br>44-78-00 | Биш көнлек эш атнасы 6:00 дән 18:00 гә кадәр<br>Кабул итү сәгатьләре: дүшәмбе 16:00-18:00<br>җомга 8:00-10:00 |
| Таҗетдинова Лилия Габделфәт кызы | Мөдир | Түбән Кама шәһәре, Чишмале ур., 21<br>https://edu.tatar.ru/nkamsk/org6870 | (88555)<br>44-78-01 | Биш көнлек эш атнасы 6:00 дән 18:00 гә кадәр<br>Кабул итү сәгатьләре: дүшәмбе 16:00-18:00<br>җомга 8:00-10:00 |